| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 10 2020 № 639

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай ш. т. п. 11 км ерак һәм аз торак пунктларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»19.11.2009 ел, №784 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай ш. т. п. 11 км ерак һәм аз торак пунктларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 19.11.2019 ел, №784 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай ш. т. п. 11 км ерак һәм аз торак пунктларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенең 2.7. пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар-юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар - шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген индивидуаль эшкуар сыйфатында туктатырга тиеш түгел».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм милек белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Моратшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов